| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.01. 2021 Олы Кайбыч ав. 1

2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халыкка күрсәтелә торган торак һәм коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын һәм алар өчен түләү күләменең нигезле булуын арттыру чаралары турында» 2010 елның 9 апрелендәге 250 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре тарифларын, кушымтада каралганча, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.
3. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен тарифларны раслау турында» 2020 елның 16 гыйнварындагы 27 номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «2020 елга халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләре өчен тарифларны раслау турында» 2020 елның 16 гыйнварындагы 27 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 25 декабрендәге 557 номерлы карарын.

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н. Макаров

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «15» 01.
1 номерлы карарына
кушымта

## 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 31 декабренә кадәр халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар

| т/б № | Түләү атамасы | Хезмәт үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлегенә тариф (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 елның 1 гыйнварыннан 2021 елның 30 июненә кадәр | 2021 елның 1 июленнән 2021 елның 31 декабренә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 0,76 | 0,79 |
| 2. | Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертем | күпфатирлы йорттагы бинаның милекчесенә караган гомуми мәйданы кв. м. аена | 3,16 | 3,29 |
| 3. | Йорт эчендәге су үткәргеч-канализация челтәрләренә агымдагы ремонт һәм карап тоту | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 2,03 | 2,11 |
| 4. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 1,10 | 1,14 |
| 5. | Найм буенча база ставкасы | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 5,00 | 5,00 |
| 6. | Тышкы фасад эчендәге газүткәргечләргә техник хезмәт күрсәтү | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 0,50 | 0,52 |
| 7. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 1,08 | 1,12 |
| 8. | Җылләтү каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | аена торак урынның гомуми мәйданының кв.м. өчен | 2,12 | 2,20 |